ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.11.2023 Олы Кайбыч ав. № 489

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында көнбатыш яктан Олы Кайбыч авылының әйләнмә автомобиль юлын төзү» объектын ызанлау проекты һәм территорияне планлаштыру проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

Халыкның тормыш эшчәнлегенең уңай шартларына хокукларын, җир кишәрлекләре хокук ияләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында көнбатыш яктан Олы Кайбыч авылының әйләнмә автомобиль юлын төзү» объектын ызанлау проекты һәм территорияне планлаштыру проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

2. 2023 елның 04 декабрендә 10.00 сәг тә Кайбыч районы, Олы Кайбыч ав., Кояшлы бульвар, 7 й. адресы буенча урнашкан Иҗтимагый үзәк бинасының актлар залында «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында көнбатыш яктан Олы Кайбыч авылының әйләнмә автомобиль юлын төзү» объектын ызанлау проекты һәм территорияне планлаштыру проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрергә.

3. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында көнбатыш яктан Олы Кайбыч авылының әйләнмә автомобиль юлын төзү» объектын ызанлау проекты һәм территорияне планлаштыру проекты материаллары (текст өлеше һәм графиклар өлеше) белән эш көннәрендә 8.00 сәг тән 17.00 сәг кә кадәр Кайбыч районы, Олы Кайбыч ав., Кояшлы бульвар, 7 й., 2 кат, 209 нчы кабинет адресы буенча танышырга мөмкин.

3.1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында көнбатыш яктан Олы Кайбыч авылының әйләнмә автомобиль юлын төзү» объектын ызанлау проектын һәм территорияне планлаштыру проекты буенча тәкъдимнәр һәм

кисәтүләр җыю урыны итеп Кайбыч районы, Олы Кайбыч ав., Кояшлы бульвар, 7 й., 2 кат, 209 нчы кабинетны билгеләргә.

4. Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегенә:

- «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында көнбатыш яктан Олы Кайбыч авылының әйләнмә автомобиль юлын төзү» объектын ызанлау проектын һәм территорияне планлаштыру проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында мәгълүмат урнаштырырга;

- әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга;

- гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Кайбыч муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең төзелеш һәм ТКХ буенча урынбасары Б.Р.Сәлаховка йөкләргә.

Җитәкче А.Н. Макаров